Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

__21.01.2022______ г. Менделеевск № ___24_______

«2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
физик культура һәм спортны үстерү»
район муниципаль программасын раслау турында

Менделеевск муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» район муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А.Н. Сәфәралинга йөкләргә.

Җитәкче: Р.И. Беляев

КИЛЕШЕНГӘН:
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
вазифаларын башкаручы А.Н.Сәфәргалин
ФБП рәисе М.В. Григорьев
Юридик бүлек җитәкчесе Е.С. Царева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның
21 гыйнварендагы 24 номерлы карарына
кушымта

«2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
физик культура һәм спортны үстерү»
район муниципаль программасы

Менделеевск ш. 2022 ел

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» район муниципаль программасы (алга таба –Программа) |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны үтәүче | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе<br>«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе<br>«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе<br>Менделеевск муниципаль районының социаль яклау идарәсе |
| Программаның максаты | 1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.<br>2. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүдә халыкның агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын формалаштыру.<br>3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.<br>4. Менделеевск муниципаль районының барлык халкы белән сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру. |
| Программаның бурычлары | 1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләренә тотрыклы кызыксыну формалаштыру;<br>2. Спортчыларны әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, шәһәрнең спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү;<br>3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының резерв спорт командалары һәм югары класслы спортчыларын әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;<br>4. Халыкның төрле категорияләрен һәм төркемнәрен физик тәрбияләү системасын модернизацияләү;<br>5. Менделеевск районында яшәүчеләр өчен кулай булган физик культура һәм спорт өлкәсе инфраструктурасын булдыру һәм үстерү; |

| | |
|---|---|
| | 6. Балалар һәм яшьләр өчен спортның төрле төрләре буенча укыту-спорт чаралары уздыру өчен шартлар булдыру;<br>7. Халыкнын яшәү урыны буенча спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар булдыру;<br>8. Гомум шәһәр спорт-массакүләм чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар булдыру;<br>9. Шәһәр халкының төрле категорияләре өчен массакүләм спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тәэмин итү;<br>10.Физик культура һәм спортны сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак пропагандалауны камилләштерү;<br>11.Яшьләр инфраструктурасының үсеше һәм тотрыклы эшләвен тәэмин итү;<br>12.Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә итүне, кадрлар белән, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2022 -2024 еллар |
| Программаны финанслау чыганаклары | Җирле бюджет акчалары – 74 117,7 мең сум.<br>Бюджеттан тыш акчалар – 4 210,00 мең сум.<br>Республика акчалары– 1 548,88 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2024 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләр көтелә:<br>Район халкының физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр санын 60,2 процентка җиткерү;<br>халыкка түләүле физкультура-спорт хезмәтләре күрсәтү күләмен арттыру һәм сыйфатын арттыру;<br>гражданнарның авырулар санын киметү, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр һәм чакырылу яшендәге егетләрнең физик әзерлеген яхшыртырту;<br>бөтенроссия һәм халыкара ярышларда чыгыш ясаучы Татарстан Республикасы спортчылары санын арттыру;<br>физик культура һәм спорт чаралары мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик тернәкләндерүнең һәм социаль адаптацияләүнең ролен күтәрү |

I бүлек. Мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән Программа

Әлеге Программа «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» максатчан программасын, 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү стратегиясе нигезләмәләрен исәпкә алып эшләнгән. Моннан тыш, программа 2030 елга кадәр район демографик үсешенең Комплекслы программасын гамәлгә ашыру буенча төп чараларның берсе булып тора.

Программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, физик активлыкны һәм халыкның барлык төркемнәренең әзерлеген арттыруга, ял һәм сәламәт яшәү өчен шартлар тудыруга, спорт резервын әзерләүгә һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы спортчыларының республика, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларына юнәлдерелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Спорт инфраструктурасын үстерү һәм эзлекле камилләштерү өлкәсендә уңай үзгәрешләр күзәтелә. 2021 ел ахырына 115 спорт корылмасы эшли.

Менделеевск муниципаль районында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүне арттыру буенча эш алып барыла.

Менделеевск муниципаль районында спортның 14 төре буенча 4 спорт учреждениесе эшли, анда 35 тренер җитәкчелегендә 1 352 бала шөгыльләнә, шул исәптән 4 тренер авыл җирлекләрендә (Енабердино – волейбол, Иске Гришкин – волейбол, Турай – спорт көрәше, Монаш – җиңел атлетика) эшли. Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр күп кенә халыкара, бөтенроссия һәм республика ярышларында катнашалар һәм җиңү яулыйлар

Шул ук вакытта тармакның алга таба үсешенә түбәндәге мәсьәләләр тоткарлык тудыра:

1. Менделеевск муниципаль районында яшәүчеләрне физик культура белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү җитәрлек түгел.

Менделеевск муниципаль районында 3 яшьтән 69 яшькә кадәрге Менделеев муниципаль районында яшәүчеләрнең 53,1 проценты даими рәвештә физик культура белән шөгыльләнә.

Шуңа бәйле рәвештә төп бурычларның берсе-төрле яшь төркемнәрендә һәм категорияләрендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен иң югары дәрәҗәдәге уңай шартлар тудыру.

2. Менделеевск муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары өчен югары класслы спортчыларны һәм спорт резервын әзерләү системасының камил булмавы югары казанышларга ирешүгә ярдәм итми.

3. Спортның өстенлекле төрләре, шул исәптән адаптив, җитәрлек финанс, медицина һәм фәнни тәэмин ителеше булмау Менделеев спортчыларын бөтенроссия һәм халыкара ярышларга максатчан әзерләүне тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирми.

Физик культура һәм спорт үсешен тоткарлаучы факторлар булып түбәндәгеләр:

- мәгариф учреждениеләрендә, предприятиеләрдә һәм оешмаларда спорт клублары челтәрен үстерүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

- физик культураны һәм спортны, сәламәт яшәү рәвешен актив пропагандалау булмау;

- югары класслы спортчыларны һәм тренерларны  матди кызыксындыруга нигезләнгән  системаның гамәлгә ашырылмавы;

- яшәү урыннары буенча предприятиеләрдә, оешмаларда тренерлар-укытучыларның, спорт оештыручыларының саны җитәрлек булмау.

Күрсәтелгән мәсьәләләрне максатчан программа  ысулы белән комплекслы хәл итмичә, яшәү рәвешен үзгәртмичә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнү өчен шартлар тудырмыйча торып, халыкның сәламәтлеге һәм социаль демография белән бәйле тискәре вәзгыять тагын да катлаулана бара.

Максатчан программа  ысулының түбәндәге төп өстенлекләрен аерып күрсәтергә мөмкин:

- проблеманы хәл итүгә комплекслы якын килү;

- Программаны үтәүчеләр һәм катнашучылар арасында вәкаләтләр һәм җаваплылык бүленеше;

- Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен тиешенчә планлаштыру, тикшереп тору һәм мониторинглау.

Программа белән нәтиҗәсез идарә итү максатка ирешмәүгә һәм Программаның бурычларын үтәмәүгә китерергә мөмкин.

Финанс куркынычын чикләүнең махсус ысулы булып, ел дәвамында ирешелгән нәтиҗәләргә бәйле рәвештә программа чараларына һәм максатчан күрсәткечләргә  ел саен төзәтмәләр  кертү тора.

Максатчан программа  ысулын куллануның административ куркынычы Менделеевск муниципаль районы башкарма хакимияте органнары һәм оешмалары тарафыннан программа йөкләмәләрен тулы күләмдә кулланмаудан гыйбарәт, бу физик культура һәм спорт өлкәсен тигез үстермәүгә китерәчәк.

Әлеге куркынычларны чикләү алымнары булып:

- Программаны финанслау барышы турындагы мәгълүматны кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүне стимуллаштыручы механизм буларак даими һәм ачык бастырып чыгару;

- Программа чараларына үз вакытында корректировка;

- Программа чараларын үтәүне нәтиҗәле контрольдә тоту һәм Программаны гамәлгә ашыруга агымдагы идарә механизмын камилләштерү тора

## II бүлек.   Программаның төп максаты һәм бурычлары

Программаның төп максаты:

- Массакүләм физик культураны һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Менделеевск муниципаль районының спорт имиджын алга җибәрү.

Күрсәтелгән мактсаларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны утәү кирәк

1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләренә  кызыксыну уяту;

2. Менделеевск муниципаль районында яшәүчеләр өчен кулай булган физик культура һәм спорт өлкәсендәге инфраструктураны булдыру һәм үстерү;

3. Халыкның төрле категорияләрен һәм төркемнәрен физик тәрбияләү системасын модернизацияләү;

4 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының резерв спорт командалары һәм югары класслы спортчыларын әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;

5. Физик культураны һәм спортны сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак пропагандалауны камилләштерү;

6. Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә итүне, кадрлар белән, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү.

III бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җирле бюджет акчаларын, бюджеттан тыш акчаларны файдалану күздә тотыла.

« «Физик культура һәм спорт» тармагы буенча

2022 ел – 74 117,7 мең сум, шуның 500,0 мең сумы чаралар үткәрүгә

Бюджеттан тыш «Нептун» СК МБУ- 1 500,0 мең сум, «Айсберг» СМ МБУ - 2 000,0 мең сум, «Батыр» СМ МБУ - 650,0 мең сум, «Фаворит» ат спорт мәктәбе - 60,0 мең сум.

IV бүлек. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

“Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ Программада катнашучыларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм координацияләү өчен җаваплы башкарма хакимият органы булып тора. Ул тармак учреждениеләре, предприятиеләр җитәкчеләре һәм башка оешмалар белән берлектә:

- программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру механизмын төгәлләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерли;

- максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларның квартал буенча бүленеше ачыклый.

V бүлек. Программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

1. Программаны гамәлгә ашыруның социаль нәтиҗәсе:

- спорт инфраструктурасын тотрыклы үстерү һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру;

- халыкта, бигрәк тә балаларда, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә кызыксыну һәм ихтыяҗ булдыру, сәламәт яшәү рәвешен кертү, физик культура, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше өлкәсендә белемлелек дәрәҗәсен күтәрү күнекмәләрен формалаштыру;

- гражданнарның социаль хәленә бәйсез рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен тигез шартлар тудыру;

- физик культура һәм спорт ярдәмендә яшьләр арасында наркоманияне, алкоголизмны, тәмәке тартуны һәм хокук бозуларны профилактикалауның нәтиҗәле системасын булдыру;

- республика спортчыларының Россия, халыкара ярышларда һәм олимпия уеннарында югары нәтиҗәләргә ирешү өчен нәтиҗәле система һәм шартлар тудыру;

- милли төрләрен дә кертеп, төрле спорт төрләрен популярлаштыру һәм үстерү;

- олимпия спорт төрләрен үстерү һәм Россия җыелма командаларына спорт резервын әзерләү;

- спортның төп төрләрен үстерү һәм физик культура, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр спорты белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру.

2. «Программаның максатчан күрсәткечләре»

| № п/п | Максатчан күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлеге | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Системалы рәвештә спорт белән шөгыльләнүче халыкның чагыштырма саны | % | 53,1 | 55,5 | 58,2 | 60,2 |
| 2 | Үткәрелгән спорт чаралары саны | Ед. | 416 | 446 | 476 | 506 |
| 3 | Алган медальләр саны | Ед. | 246 | 261 | 276 | 291 |
| 4 | Спорт төзелмәләре саны | Ед. | 115 | 115 | 117 | 119 |

VI бүлек. Программалы чаралар исемлеге

| № п/п | Чаралар | Башкаручылар | Үтәү вакыты | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
| **1. 1.Физкультура-массакүләм эшне үстерү, халыкның хәрәкәт активлыгын арттыру** | | | | | | | |
| 1.1 | Физкультура – сәламәтләндерү һәм спорт чаралары комплекслы планы эшләү:<br>-тору урыны буенча<br>-эш һәм уку урыны буенча<br>-авыл җирендә яшәүчеләр белән<br>- инвалидлар белән эшләгәндә<br>-җәмәгать оешмалары һәм төрле юнәлештәге клублар белән<br>- спорт ветераннары белән | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | - | - | - | - |
| 1.2 | Яшәү урыны буенча төрле яшьтәге халык катнашында физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрү | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 90,0 | 90,0 | 90,0 |
| 1.3 | Мөмкинлекләре чикләнгән | «МҮРХ» дәүләт | 2022-2024 | Җирле | 25,0 | 25,0 | 25,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кешеләр арасында спорт эшен оештыру, адаптив физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, өлкән яшьтәге кешеләрне сәламәтләндерү физкультурасына җәлеп итү | автоном сәламәтлек саклау учреждениесе «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Социаль яклау бүлеге | | бюджет | | | |
| 1.4 | Халык өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә шартлар тудыру | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе ТР Менделеевск районы буенча | 2022-2024 | Җирле бюджет | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | эчке эшләр министрлыгы бүлеге | | | | | |
| 1.5 | Физкультура-савыктыру һәм спорт эшен иң яхшы оештыруга гомуми белем бирү учреждениеләре арасында смотр-конкурслар үткәрү | «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| **2. Сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау** | | | | | | | |
| 2.1 | Стационар һәм мәктәп яны лагерьларында физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрү | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «МҮРХ» дәүләт автоном сәламәтлек | 2022-2024 | Җирле бюджет | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | саклау учреждениесе | | | | | |
| 2.2 | Балигъ булмаганнар комиссиясендә хисапта торучы балигъ булмаганнарны мәктәп коллективларының иҗади эшчәнлегенә җәлеп итү, төрле мәдәни-массакүләм, спорт чараларына һәм секцияләренә җәлеп итү | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе «Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 17,0 | 17,0 | 17,0 |
| 2.3 | Тәмәке тартуны, алкоголизмны, наркоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм уздыру | «МҮРХ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | | | | | |
| **3. Югары казанышлар спортын үстерү** | | | | | | | |
| Ярышлар һәм конкурслар оештыруның һәм уздыруның нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | |
| 3.1 | Ел саен смотр – конкурслар оештыру һәм уздыру:<br>-Спортның Олимпия төрләре буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>- Олимпия төрләренә кермәгән спорт буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>-спорт уен төрләре буенча иң яхшы команда | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 35,0 | 35,0 | 35,0 |
| 3.2 | Әйдәп баручы спортчыларның, район җыелма һәм клуб командаларының | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль | 2022-2024 | Җирле бюджет | 110,0 | 110,0 | 110,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашуы | казна учреждениесе | | | | | |
| 3.3 | Югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне өчен тренерларга, шулай ук спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчыларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү | Спорт мәктәпләре | 2022-2024 | ТР бюджеты | 1300,0 | | |
| 3.4 | муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләгәне өчен акчалата түләү | Спорт мәктәпләре | 2022-2024 | ТР бюджеты | 35,0 | | |
| **4. Яшьләргә граждан булу, рухи-әхлакый тәрбия бирү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | |
| 4.1 | Яшьләргә хәрби-патриотик, рухи-әхлакый, экологик тәрбия бирү өлкәсендә район конкурслары, проектлар һәм программалар оештыру | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль | 2022-2024 | Җирле бюджет | 8,0 | 8,0 | 8,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | казна учреждениесе «Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Район хәрби комиссариаты | | | | | |
| 4.2 | Илебез тарихының истәлекле даталарына бәйле чаралар оештыру һәм уздыру | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе «Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 | Җирле бюджет | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 4.3 | Ел саен үткәрелә торган бәйрәмнәрдә (Сабантуй, физкультура көне, шәһәр көне) спорт чараларын | «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль | 2022-2024 | Җирле бюджет | 110,0 | 110,0 | 110,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру һәм уздыру | казна учреждениесе | | | | | |
| **5. Материаль-техник базаны ныгыту** | | | | | | | |
| 5.1 | Спорт юнәлешендәге учреждениеләр өчен спорт инвентарьлары сатып алу | ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | 2022-2024 | ТР акчалары | 213,88 | | |
| 5.2 | Спорт залларына капиталь ремонт | Подрядчы оешмалар | 2022-2024 | Бюджеттан тыш акчалар | | | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | | | | **2066,88** | **500,00** | **500,00** |